САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 25 17.12.2015
№ _________от ______________

# КАРАР

«Социаль-мәдәни объектлар урнашкан урыннарга якын территорияләрдә, гражданнар күпләп тупланган урыннарда һәм югары куркыныч чыганаклары урнашкан урыннарда алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәве турында» Саба муниципаль районы Советының 2013 елның 20 маендагы 198 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында» 1995 елның 22 декабрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган гражданнар һәм югары куркыныч чыганаклары урнашкан урыннарны билгеләү, шулай ук алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган территорияләрнең кайбер оешмаларына һәм объектларына якын урнашкан җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү турында» 2012 елның 27 декабрендәге 1425 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

– «Социаль-мәдәни объектлар урнашкан урыннарга якын территорияләрдә, гражданнар күпләп тупланган урыннарда һәм югары куркыныч чыганаклары урнашкан урыннарда алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәве турында» 2013 елның 20 маендагы 198 номерлы Саба муниципаль районы Советы карары;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2013 елның 26 июлендәге 206 номерлы карары «Социаль-мәдәни объектлар урнашкан урыннарга якын территорияләрдә, гражданнар күпләп тупланган урыннарда һәм югары куркыныч чыганаклары урнашкан урыннарда алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәве турында» 2013 елның 20 маендагы 198 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында».

2. Әлеге карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
Башлыгы Р.Н. Минниханов